| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.11.2022 г. Казань № 276-13/э-2022

«Электр челтәрләре» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2020 № 537-21/э-2020 карары белән билгеләнгән озак сроклы индивдуаль тарифларга 2023 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (куллану) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүгә кирәкле тулай табышны озак сроклы индексацияләү алымын кулланып билгеләнә торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау хакында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 9 ноябрендәге 34-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендәге челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүгә озак сроклы аерым тарифларга һәм җайга салынулы оешмаларының кирәкле тулай табышына 2023 ел өчен төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2021-2025 елларга «Электр челтәрләре» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара

исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә индивидуаль тарифлар билгеләү турында» 17.12.2020 № 537-21/э-2020 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 01.12.2021 № 433-20/э-2021 карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2021 № 537-21/э-2020
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
09.11.2022 № 276-13/э-2022
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы «Электр челтәрләре» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2021 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр календарь буенча бүленгән индивидуаль тарифлар

| Т/с | Челтәр оешмасының исеме | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1. | «Электр челтәрләре» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе | 2021 | 121 935,17 | 126,30 | 0,57157 | 121 935,17 | 126,30 | 0,57157 |
| | | 2022 | 108 190,33 | 131,21 | 0,57772 | 108 190,33 | 131,21 | 0,57772 |
| | | 2023 | 137 446,65 | 149,05 | 0,71759 | 137 446,65 | 149,05 | 0,71759 |
| | | 2024 | 137 530,76 | 131,36 | 0,63358 | 137 530,76 | 131,36 | 0,63358 |
| | | 2025 | 141 515,67 | 131,36 | 0,64813 | 141 515,67 | 131,36 | 0,64813 |

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2021 № 537-21/э-2020
карарына 3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
09.11.2022 № 276-13/э-2022
карары редакциясендә)

2021-2025 елларга Татарстан Республикасы «Электр челтәрләре» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенең (югалтуларны исәпкә алмыйча) кирәкле тулай кереме

| т/с | Татарстан Республикасындагы челтәр оешмасының исеме | Ел | Челтәр оешмасының кирәкле тулай табышы (югалтуларны исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1. | «Электр челтәрләре» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе | 2021 | 173 918,58 |
| | | 2022 | 154 314,03 |
| | | 2023 | 196 042,91 |
| | | 2024 | 196 162,87 |
| | | 2025 | 201 846,63 |

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге